# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл жирлеге Таш-Чишмә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“04” ноябрь 2019 ел. № 02

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 04 ноябрендә «Сез 2020 елда Өҗем авыл жирлеге Таш-Чмшмә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның жирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1. Территорияне төзекләндерү:
   - Таш-Чишмә авылында күлне төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, Транспорт хезмәтләре өчен түләү һәм эш өчен түләү);
   - Таш-Чишмә, Иске Өҗем авыллары территорияләрен төзекләндерү һәм чистарту (агач кисү, транспорт хезмәтләре күрсәтү);

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтижәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 267 (икейөз алтмыш жиде) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 179 (йөз житмеш тугыз) кеше.

Тавыш бирү нәтижәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 179 (йөз житмеш тугыз) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл жирлеге Таш-Чишмә авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.
2. “Сез 2020 елда Өҗем авыл җирлеге Таш-Чишмә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның жирле

әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме: - “Территорияне төзекләндерү:

- Таш-Чишмә авылында күлне төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, Транспорт хезмәтләре өчен түләү һәм эш өчен түләү);

- Таш-Чишмә, Иске Өҗем авыллары территорияләрен төзекләндерү һәм чистарту (агач кисү, транспорт хезмәтләре күрсәтү)”мәсьәләсен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Таш-Чишмә авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Таш-Чишмә авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Өҗем авыл җирлеге башлыгы: Вәлиев А.Т.